СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Ташкичү авыл җирлеге Советы**
**Карары**

**«20» май 2025 ел** **№ 24**

**Татарстан Респбликасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының “Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә хәрби исәп буенча белгечләргә хезмәт өчен түләү турындагы нигезләмәне раслау турында” 2024 елның 19 декабрендәге 19 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

РФ Хөкүмәтенең “Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр турында” 2006 елның 29 апрелендәге 258 номерлы карары, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 144 статьясы, Россия Федерациясе Оборона министрының “Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрби частьләре һәм оешмалары гражданлык персоналына (хезмәткәрләренә) хезмәт өчен түләү системасы турында” 2024 елның 29 сентябрендәге 595 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының “Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә хәрби исәп буенча

белгечләргә хезмәт өчен түләү турындагы нигезләмәне раслау турында” 2024 елның 19 декабрендәге 19 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада “РФ оборона министрының “Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрби частьлары һәм оешмалары гражданлык персоналының (хезмәткәрләренең) хезмәтенә түләү системасы турында” 2019 елның 18 сентябрендәге 545 номерлы боерыгы белән» дигән сүзләрне “РФ оборона министрының “Россия Федерациясе Хәрби Көчләре хәрби частьләре һәм оешмаларының гражданлык персоналының (хезмәткәрләренең) хезмәтенә түләү системасы турында” 2024 елның 30 сентябрендәге 595 номерлы боерыгы белән” дип үзгәртергә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Хабибуллин